# БЕР КАРТИНА ТАРИХЫ

## 1943 елның сентябрендә, Кама елгасындагы шторм вакытында үлем белән көрәшеп, 14 яшьлек киномеханиклар исән-сау калалар

Роза ХӘМИДУЛЛИНА

**Бер уңган гел уңган, диеп, тикмәгә генә әйтмәгән халык. Шәһәребездә яшәп иҗат итүче Зөфәр абый Сәгыйтовның композитор булуын белә идем. Ә ул, яңа гына ясап төгәлләгән картинасын китапханәбезгә бүләк итәр өчен, безне өенә чакырды. Зөфәр Ярулла улы үзе кичергән хистойгыларын шушы картинада күрсәтергә теләгән. Сиксән елга якын вакыттан соң, авторның күңел төпкелләрен ертып туган картина ул.**



Рәсемдә: Зөфәр Сәгыйтов китапханәчеләр Роза Хәмидуллина (уңда), Наилә Гыйльметдинова (сулда)

Картинада сурәтләнгән вакыйга сугыш елларына барып тоташа. 1943 елның сентябрендә, Кама елгасындагы шторм стихиядә үлем белән көрәшеп, 14 яшьлек киномеханиклар исән-сау калалар.

Егетләрнең берсе Зөфәр – өлкән киномеханик һәм Исрафил Нәбиуллин белән Мидхәт Йосыпов – ярдәмчеләр. Аларга Яр Чаллы кинотеатры директоры Иван Григорьевич Агафонов Алабугадан өч фильм алып кайтырга куша. Киномеханиклар, Чулман елгасын кечкенә көймәдә үтеп, Алабугага юл тоталар, бару юлы матур була, күзге кояш күктән елмая. Көймә белән идарә итүче Зөфәр үз эшен яхшы башкара, егетләргә дә ишкәк белән ишү серләрен өйрәтеп бара.

Аларга Алабуга прокат бүлегендә склад мөдирен ике сәгатьләп көтәргә туры килә. Бу ике сәгать вакыт егетләрнең гомерен чак кына кыскартмый кала. Фильмнарны көймәгә төяп, кайтыр юлга чыгалар. Кама борылышын үтеп, Бәтке авылы янында караңгы төшә башлый. Кинәт көчле җил күтәрелә, күк йөзе кап-кара төс ала, болытлар куерганнан-куера, яшене дә озак көттерми. Егетләрнең ишкәгенә каршы зур дулкыннар көймәне төрле яклап йолкый, коеп яңгыр ява башлый. Дулкыннар көймәне күмеп китмәсен өчен, аны дулкыннарга каршы, ар ярга таба тотарга кирәк. Зөфәр бик игътибар белән идарә итә, югыйсә, барысы да төпкә китәчәк. Дулкыннар үз эшләрен башкара, көймәгә су керә, бер үк вакытта ишкәкләрне ишәргә дә, кергән суны түгәргә дә туры килә. Озак та көттерми, төн туа. Әле яхшы, яшен, барлык көченә шартлатып, көймәчеләргә ар якны яктырткалап ала. Зөфәргә яңгырның шавы астында ишкәкчеләргә ишетелерлек көчле тавыш белән җитәкчелек итәргә туры килә.

Егетләрнең берсе, көймә белән янәшәдә шарт-шорт килеп шартлаган яшеннән куркып, ишкәкне ычкындырып суга төшереп җибәрә. Шулвакыт ике кулы белән битен каплаган Мидхәтнең: “Әни, без беттек!” – дигән сүзләре ишетелә. Бер ишкәк белән генә ярга барып җитеп булмаганны Зөфәр бик яхшы аңлый. Ул, үзен кулга алып, кинәт суга сикереп төшә. Бар көченә көймәне ярга этеп, кырыйдан йөзеп бара. Аның балачактан суда балык кебек яхшы йөзүе монда бик ярдәм итә. Көймәне капландырмый шулай йөзеп барырга туры килә аңа. Елганы озак кичәләр егетләр. Бераздан Зөфәрнең аяклары су төбенә кагылып китә. Ул үзен-үзе белештерми: “Җир, җир”, – дип кычкырырга көч таба. Мидхәт беренче булып ярга сикереп төшә дә шатлыгыннан: “Әни, без исән, без исән”, дип кабатлый. Әмма өйгә кадәр юл бик ерак була әле. Җилгә каршы елга ярыннан көймәдә бару мөмкин түгел. Монда да Зөфәрнең зирәклеге булыша. Бурлаклар кебек яр буйлап көймәне тартып кайтырга булалар. Көймәдәге озын чылбыр да эшкә ярап куя. Зөфәр егетләрнең кәефләрен күтәрергә теләп, көймәне өстерәп бару җиңелрәк булсын өчен, җырларга тәкъдим итә. Башта «Интернационал» җырын җырлыйлар, аннары – «Смело товарищи в ногу». ...Ниһаять, Нефтеваза, аннан Үзәк урам башына да якынлашалар. Башта фильмнарны бушаталар, аннан көймәне чыгарып куялар да үзләре Үзәк урам буйлап Иван Григорьевичның өенә күтәреләләр. Иван Григорьевич та төне буе йокламый, балаларны көтә. Аларны исән-сау күрү шатлыгыннан, тунган кулларын кыса-кыса, рәхмәтләр укый. Ә иртән афиша язып элә: “Бүген – «Она защищает Родину» дигән яңа нәфис фильм”.

Егетләр шушы адымнары белән сугыш елларында тылда хезмәт куйган халыкның кайгысын бераз гына булса да җиңеләйтергә тырышалар. Киномеханик булып эшләү дәверендә төрледән-төрле кызыклы да, гыйбрәтле дә хәлләр белән очрашырга туры килә Зөфәр абыйга.

...Үзе дә уйламаганда киномеханик булып китә ул. Мулланур Вахитов исемендәге мәктәптә укый Зөфәр. 1943 елны мәктәптә укулар тәмамлану алдыннан, Иван Григорьевич физика фәненнән бишле билгеләренә генә укучы өч малайны сайлап ала. Алар арасында Зөфәр дә була. Курслар үткәч, аны җитәкче итеп куялар. Авылдан-авылга барып, кино күрсәтеп йөриләр алар. Ә Шакирҗанов Мидхәт белән бергә Сарманның үзендә кино күрсәтү җайланмасын да оештыралар. Шунда яшәп, бер еллап фильмнар күрсәтәләр. Киногa килгән халык гел Зөфәрнең игътибар үзәгендә була. Ул һәрдаим аларны күзәтә. Авыл халкы төрлесе төрле вакытта киләләр, кайвакытларда халыкның җыелып бетүен озаклап көтеп торырга туры килә. Күпвакыт кешеләр кино карарга бик арып килә, механик егет ничек тә булса аларны ял иттерергә тырыша. Авыл халкы газета алмый, радио барлык җирдә дә булмый. Китапханәләр дә мәктәпләрдә генә булды кебек, диеп искә ала Зөфәр абый. Алдан килгәннәрнең күңелләрен күтәрү өчен, ул сәхнәнең ике ягына плакатлар язып куя. Хәзер дә кайберләрен хәтерендә саклый ул: “Из всех искусств для нас важнейшим является кино” (Ленин). “Наше дело правое, мы победим” (Сталин). Алдан килгән тамашачы плакатны укый-укый ятлап бетерә. Клуб халык белән шыгрым тулгач, башта унике минутлык сугыш яңалыклары күрсәтелә. Халык бик игътибар белән карый, кул чаба. Аннан төп кино башлана. Ул елларда халыкның бик яратып йөри торган кинолары була. “Чапаев” киносы гел тулы залларда үтә. “Радуга”, “Два бойца”, “Депутат Балтики”, “Парень из нашего города”, “Свинарька и пастух”, “Истребитель” һәм башкалар.

Авылдан-авылга йөргәндә кызык хәлләр белән еш очрашырга да туры килә аларга. Бер авылдан икенчесенә күчкәндә арбага җигәргә атлар җитешми, күп вакытта үгезләр, сыерлар бу вазифаны үти. Бервакыт “күрше авылга барабыз, диеп чыксак, үгезләр урынында ике хатын-кыз җигелгән иде. Алар – алдан, без икәү арттан этеп бардык”, дип, елмаеп искә алды Зөфәр абый. Авыл халкын бераз гына сугыштан оныттырып тору теләге шулкадәр көчле булган аларда. “Бервакыт үгез җигелгән арба белән авылга килеп кердек, – дип хатирәләрен яңартты ул – анда безне өрә-өрә этләр каршы алды. Этләрне күрү белән үгезебез аларны куа башламасынмы. Авылның бер тыкрыгы да калмады, бары тик этләрне күздән югалткач гына, үгезне туктата алдык. Соңыннан гына билгеле булды, бу үгезнең аягын кайчандыр этләр тешләгән булган икән, шуның үчен алып, ул һәрбер этне шулай куып куркыта торган булып калган”.

... Ә бервакыт үгезләре киреләнә, үгез куып килүче егет нәрсәләр белән генә алдалап карамый. Кире мал урыныннан кузгалырга да уйламый. Егет аның койрыгын күтәреп, салам тыгып куя да ут төртеп җибәрә. Үгез шуны гына көткәндәй чаба башлый. Авылга бик тиз килеп җитәләр. Инде үгез туктамый. Егетләр, дилбегәне өчәүләп тартып, үгезне карга батыралар, үзләре чанадан төшеп калалар, кино ящикләре дә төрле якларга тарала. Малкайны кар көртеннән чыгарырга авыл халкы булыша.

Киноны халык рәхәтләнеп карый. Соңыннан балалар, хатын-кызлар өйләренә ашыга. Ә сугышка алу чорыннан узган, фронттан яраланып кайткан ир-ат, кино тәмамланганнан соң, әңгәмәләр корып, сөйләшеп арыганнан соң гына өйләренә таралалар. Киномеханикларны ул вакытларда төрле гаиләләргә кунарга кертәләр. Аларны ашатыр өчен, авыл советы бәрәңге, тоз, он, арыш ипие, сирәк кенә сөт тә яздырып бирә. Ләкин бу ашамлыклар тулысы белән егетләргә тотылмый. Бер авылда хәтта бал да бирәләр, ләкин гаиләсе зур булган фатир хуҗасы егетләрне ашатырга уйламый да. Кич эштән кайткан егетләрнең ашыйсы килү теләкләре шулкадәр көчле була, алар балны, бик тәмләп, хуҗабикә күрмәгәндә ашап бетерәләр. Ә иртәгесе көнне яңа гына аертылган бал тамак төпләрен яндырганлыктан сөйләшә дә алмыйлар.

Зөфәр Ярулла улы Сәгыйтов, сугыш елларында киномеханик булып эшләп, авыл халкының кайгысын җиңеләйтү өчен күп көч куя. Шул елларның кайтавазы булып, әлеге картина туган. Бөек Җиңү көне уңаеннан, бу бүләк-картина китапханәнең сәнгать бүлегендә урын алды.